СОВЕТ НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.3, с. Никифорово, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Карл Маркс ур., 3 нче йорт, Никифорово авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

№ 6-10 | «10» июнь 2016 ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлегендә индивидуаль торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга бирелә торган җир участокларының иң чик күләмнәре турында

**«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законның 4 ст. 2 пункты, Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 07 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законның 4 ст. 5 п., Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге кара кабул итте:**

1.«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 20 декабрендәге 4-38 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә.

2. Муниципаль милектә булган җирләрдән һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән гражданнарга бирелә торган җир участокларының чик (минималь һәм максималь) күләмнәрен билгеләргә:

а) 0,03 гектардан 0,15 гектарга кадәр мәйданлы шәхси торак төзелеше өчен;

б) торак пункт чикләрендә 0,03 гектардан 0,50 гектарга кадәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен.

в) торак пункттан читтә 0,08 гектардан 0,50 гектарга кадәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен.

3. Әлеге карарның 1 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм максималь) күләмнәре, әлеге карар үз көченә кергәннән соң, гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренә кагыла дип билгеләргә.

3. 2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлеге башлыгы С.Н.Степановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Никифорово авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе С.Н.Степанов